ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлегенең
Николашкино авылы торак пунктында

2020 нче елның 26 нчы ноябрь № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлегенең Николашкино авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан, 75тән өлкәнрәк яшьтәге ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2021 елда 250 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Кышкы чорда Николашкино авылында юлларны карап тоту (кардан чистарту);
- Николашкино авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;
- Николашкино авылында балалар мәйданчыгын коймалау.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яна Зареченск авыл җирлеге башлыгы С.Н. Багижева